ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28 декабрь, 2015 ел № 5/7

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибен раслау турында

Пассажирлар йөртүдә шәһәр халкының ихтыяҗларын тәэмин итү максатында һәм 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, 2015 елның 13 июлендәге «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны регуляр йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 220-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2015 елның 26 декабрендәге «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны регуляр йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законны гамәлгә ашыру хакында» 107-ЗРТ санлы Законы, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру тәртибен кушымтадагыча расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру Тәртибен раслау турында» 26/11 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2013 елның 20

сентябрендәге 71 санында, 2013 елның 25 сентябрендәге 72 санында басылган);

2) Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге «Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/11 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 39/17 санлы Карары («Челнинские известия» газетасының 2015 елның 15 маендагы 34 санында басылган).

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
5/7 нче Карарына
кушымта
28 декабрь, 2015 ел

## Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибе

### 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип 2015 елның 13 июлендәге «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны регуляр йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 220-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә регуляр муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны регуляр йөртүне оештыру (алга таба шулай ук – пассажирлар йөртүне оештыру) буенча мөнәсәбәтләрне, шул исәптән пассажирларны регуляр йөртү маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм кире кагу, юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыруны рөхсәт итү, пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыру өчен транспорт инфраструктурасы объектларын файдалану, шулай ук пассажирларны регуляр йөртүгә контрольне оештыру белән бәйле мөнәсәбәтләрне көйли.

2. Әлеге Тәртипнең көче пассажирлар йөртү килешүеннән барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә, шулай ук граждан законнары белән көйләнә торган башка милек һәм аның белән бәйле шәхси милек булмаган мөнәсәбәтләргә кагылмый.

3. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законга, 1995 елның 10 декабрендәге «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 196-ФЗ санлы Федераль законга, 2007 елның 8 ноябрендәге «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 259-ФЗ санлы Федераль законга, 2015 елның 13 июлендәге «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны регуляр йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 220-ФЗ санлы Федераль законга, РФ Хөкүмәтенең 2009 елның 14 февралендәге «Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирларны һәм багажны йөртү Кагыйдәләрен раслау турында» 112 санлы Карарына, Татарстан Республикасының 2015 елның 26 декабрендәге «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында

пассажирлар һәм багажны регуляр йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законны гамәлгә ашыру хакында» 107-ЗРТ санлы Законына, шәһәр Уставына нигезләнеп эшләнде.

4. Әлеге Тәртип таләпләре, оештыру-хокукый формаларга һәм милек формаларына бәйсез рәвештә, барлык юридик затлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәренең муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүче, юридик зат булмаган шәхси эшмәкәрләр тарафыннан үтәлергә тиеш.

5. Әлеге Тәртипнең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) пассажирлар йөртүдә шәһәр халкының ихтыяҗларын канәгатьләндерүне тәэмин итү;

2) пассажирлар йөртүнең сыйфатын арттыру;

3) пассажир йөртүченең транспорт дисциплинасын ныгыту;

4) пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру барышында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү;

5) пассажир йөртүчеләр арасында намуслы конкуренцияне тәэмин итү;

6) пассажирлар йөртү белән муниципаль идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру;

7) пассажирлар йөртүне нәтиҗәлерәк оештыруны тәэмин итү;

8) гомуми файдаланудагы транспорт хәрәкәте расписаниесенең (графигының) үтәлешен тәэмин итү;

9) Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә башка бурычлар.

6. Әлеге Тәртиптә кулланылган терминнар һәм төшенчәләр Федераль законда файдаланылган мәгънәдә кулланыла.

## 2 бүлек. Пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендә Башкарма комитет вәкаләтләре

7. Башкарма комитет вәкаләтләре:

1) халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыра һәм халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итә;

2) пассажирларны регуляр йөртүне планлаштыручы документларны раслый;

3) пассажирларны регуляр йөртү муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүнең муниципаль заказчысы функциясен башкара, муниципаль контракт төзи, котракт шартлары үтәлешен контрольдә тота һәм пассажирларны регуляр йөртү маршруты карталарын бирә;

4) җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирларны регуляр йөртү муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс оештыручы функциясен башкара һәм пассажир йөртүчеләргә пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык бирә, аларның эшчәнлеген контрольдә тота;

5) муниципаль маршрутлар реестрын алып бара, пассажирларны регуляр йөртү муниципаль маршрутларын билгели, үзгәртә һәм кире

кага;

6) автомобиль транспорты белән пассажирларны һәм багажны регуляр йөртү муниципаль маршрутлары буенча башлангыч һәм (яки) соңгы тукталыш пунктлары сыйфатында файдаланырга рөхсәт ителгән, муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан тукталыш пунктларының исемлеген билгели;

7) Татарстан Республикасының башкарма хакимияте вәкаләтле органына муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан, пассажирларны регуляр йөртү муниципальара маршрутлар буенча тукталыш пунктлары буенча тәкъдимнәр җибәрә;

8) халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатының параметрларын һәм пассажирларны регуляр йөртү муниципаль маршрутлары буенча аларның норматив әһәмиятен раслый;

9) башкарма хакимятнең федераль органнары, Татарстан Республикасының башкарма хакимияте органнары белән пассажирлар йөртүне оештыру һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә;

10) Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, һәм башка муниципаль хокукый актлар нигезендә башка вәкаләтләргә ия.

## 3 бүлек. Пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршрутын билгеләү, үзгәртү, кире кагу тәртибе

8. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршрутлары Башкарма комитетның муниципаль хокукый актлары белән пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыручы юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең (шул исәптән гади ширкәт килешүе катнашучыларының) тәкъдимнәре буенча билгеләнә, үзгәртелә, кире кагыла.

9. Пассажирларны регуляр йөртүнең маршрутларын билгеләү, үзгәртү, кире кагу турында Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты түбәндәге нигездә кабул ителә:

1) юл шартларын аларның хәрәкәт куркынычсызлыгы таләпләренә туры килүе предметына комиссия тикшерүе акты;

2) Татарстан Республикасының норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртип нигезендә төзелгән маршрутта пассажирлар агымын тикшерү акты.

10. Пассажирларны регуляр йөртүнең маршрутларын билгеләү, үзгәртү, кире кагу турында яисә маршрутларын билгеләүдән, үзгәртүдән, кире кагудән баш тарту турында Башкарма комитетның хокукый акты пассажирларны регуляр йөртүнең маршрутларын билгеләү, үзгәртү, кире кагу турында тәкъдим белән мөрәҗәгать теркәлгән көннән 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

11. Пассажирларны регуляр йөртүнең маршрутларын билгеләү, үзгәртү, кире кагу турында Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты 10 көн эчендә пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча транспорт чарасының бару юлы тасвирланган кушымта, маршрут схемасы һәм кабул ителгән карарны нигезләгән дәлил белән бергә тәкъдим белән чыккан инициаторга җибәрелә.

12. Пассажирларны регуляр йөртүнең маршрутларын билгеләүдән, үзгәртүдән, кире кагудән баш тарту турында Башкарма комитетның хокукый акты нигезләгән дәлил белән бергә тәкъдим белән чыккан инициаторга 10 көн срок эчендә җибәрелә.

13. Пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршрутлары – әлеге маршрутлар турында тиешле мәгълүмат пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршрутлары реестрына кертелгән яки мондый мәгълүматлар әлеге реестрларда үзгәртелгән көннән – билгеләнгән яки үзгәртелгән санала.

14. Пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршрутлары әлеге маршрутлар турында тиешле мәгълүмат пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршрутлары реестрыннан алынган көннән кире кагылган санала.

15. Башкарма комитет тиешле маршрутта пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыручы пассажир йөртүчеләргә пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршруты кире кагылу турында Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты кабул ителү хакында, күрсәтелгән карар гамәлгә кергән көннән алып, 180 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

## 4 бүлек. Пассажирларны регуляр йөртү маршрутлары реестры

16. Башкарма комитет пассажирларны регуляр йөртү маршрутлары реестрын Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә алып бара.

17. Пассажирларны регуляр йөртү маршрутлары реестрларына түбәндәге мәгълүматлар кертелергә тиеш:

1) тиешле реестрда пассажирларны регуляр йөртү маршрутының теркәү саны;

2) пассажирларны регуляр йөртү маршрутының тәртип саны;

3) чикләрендә әлеге маршрут буенча башлангыч тукталыш пункты һәм соңгы тукталыш пункты урнашкан пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча башлангыч тукталыш пункты һәм соңгы тукталыш пункты исеме рәвешендә пассажирларны регуляр йөртү маршрутының атамасы;

4) чикләрендә арадагы тукталыш пунктлары урнашкан пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча арадагы тукталыш пунктларының исемнәре;

5) пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча тукталыш пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәте күздә тотылган урамнарның, автомобиль юлларының атамасы;

6) пассажирларны регуляр йөртү маршрутының озынлыгы;

7) пассажирларны утырту һәм төшерү тәртибе (бары тик билгеләнгән тукталыш пунктларында яки, федераль закон белән тыелмаса, пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча юл хәрәкәте кагыйдәләре белән тыелмаган теләсә кайсы урында);

8) пассажирларны регуляр йөртү төре;

9) пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча файдаланыла торган транспорт чараларының төре һәм транспорт чараларының классы, һәрбер класстагы транспорт чараларының максималь саны;

10) пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча файдаланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикалары;

11) пассажирларны регуляр йөртә башлауның датасы;

12) пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы юридик затның исеме, урнашкан урыны, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, әгәр булса, атасының исеме (шул исәптән гади ширкәт килешүе катнашучыларының).

18. Пассажирларны регуляр йөртү маршрутлары реестрларына кертелгән мәгълүматлар шәһәрнең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекомуникация челтәрендә урнаштырыла һәм түләүсез рәвештә танышу өчен ачык булырга тиеш.

## 5 бүлек. Пассажирларны регуляр йөртү төре үзгәрү

19. Пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча гамәлгә ашырылучы пассажирларны регуляр йөртү төрен үзгәртү әлеге карар пассажирларны регуляр йөртүне планлаштыру документында каралган шартта мөмкин.

20. Башкарма комитет пассажирларны регуляр йөртү маршруты мөнәсәбәтендә пассажирларны регуляр йөртү төрен үзгәртү турында карар кабул ителү турында тиешле маршрут буенча пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашырган юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гади ширкәт килешүендә катнашучының вәкаләтле затына, күрсәтелгән карар гамәлгә кергән көннән алып, 180 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

21. Пассажирларны регуляр йөртү төре үзгәрү турында мәгълүматлар пассажирларны регуляр йөртү маршрутлары реестрына кертелә.

## 6 бүлек. Җайга салынучы тарифлар буенча пассажирларны регуляр йөртүне оештыру

22. Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итү максатында, Башкарма комитет җайга салынучы тарифлар буенча пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыру өчен муниципаль маршрутларны билгели.

23. Җайга салынучы тарифлар буенча пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыру Башкарма комитет тарафыннан, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә, Федераль закон нигезләмәләрен исәкә алып, муниципаль контрактлар төзү аша тәэмин ителә.

24. Муниципаль контракт муниципаль заказ бирүче исеменнән бирелгән һәм пассажирларны регуляр йөртүнең бөтен маршрутлары (алар мөнәсәбәтендә муниципаль заказ бирүче муниципаль контракт төзегән) буенча пассажирларның йөрү хокукын раслаган билетларны файдалануны күздә тотарга мөмкин.

25. Муниципаль заказ бирүче муниципаль контракт гамәлдә булу срогына тиешле котрактны үтәү өчен кирәкле транспорт чараларының максималь санына пассажирларны регуляр йөртү маршруты карталарын бирә.

26. Пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча пассажирларны регуляр йөртү өчен җайга салынучы тарифлар Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафынннан билгеләнә.

## 7 бүлек. Җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирларны регуляр йөртүне оештыру

27. Әлеге Тәртипнең 22 пунктында күрсәтелгән пассажирларны регуляр йөртү маршрутлары белән беррәттән Башкарма комитет җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыру өчен муниципаль маршрутларны билгели.

28. Пассажирларны регуляр йөртү муниципаль маршруты буйлап җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыру хокукы пассажирларны регуляр йөртүнең тиешле маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру таныклыгы һәм пассажирларны регуляр йөртүнең тиешле маршрут картасы белән раслана.

29. Пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршрут картасы тиешле маршрут буенча пассажирларны регуляр йөртү өчен файдаланылган һәрбер транспорт чарасына бирелә. Мондый карталарның саны пассажирларны регуляр йөртү маршрутларының тиешле реестрында күрсәтелгән тарнспорт чараларының максималь санына туры килергә тиеш.

30. Җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирларны регуляр йөртүгә таләпләр Башкарма комитетеның муниципаль хокукый акты белән эшләнә һәм раслана.

## 8 бүлек. Пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталарын бирү

31. Пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары Башкарма комитет тарафыннан бирелә.

32. Пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс (алга таба – ачык конкурс) нәтиҗәләре буенча Федераль законда билгеләнгән тәртиптә бирелә.

33. Пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары, пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән очракта, ачык кокурсны үткәрмичә бирелә:

1) әлеге Тәртипнең 42 пункты 1 һәм 2 пунктчаларында каралган хәлләр башланганнан соң, һәм ачык конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча бирелгән пассажирларны регуляр йөртү маршрутлары буенча пассажирларны йөртүне гамәлгә ашыру турында яңа таныклык нигезендә пассажирларны регуляр йөртүне гамәгә ашыру алдыннан;

2) гадәттән тыш хәлләр шартында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү максатыннан билгеләнгән пассажирларны регуляр йөртү мартшруты буенча.

34. Пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм пассажирларны регуляр йөртүнең маршрут карталары, ачык кокурсны үткәрмичә, аларны бирү өчен нигез булып торган хәлләр башланган көнне, бер тапкыр, 180 көннән артмаган срокка бирелә.

## 9 бүлек. Пассажирларны регуляр йөртүнең маршрут картасын рәсмиләштреү, яңадан рәсмиләштерү тәртибе

35. Пассажирларны регуляр йөртүнең маршрут картасы бланкта яки электрон карта формасында рәсмиләштерелә.

36. Пассажирларны регуляр йөртүнең маршрут картасы бланкы ялганнан сакланган катгый хисап документы булып тора.

37. Пассажирларны регуляр йөртүнең маршрут картасы бланкы формасы һәм аны тутыру тәртибе транспорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый көйләү буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан раслана.

38. Пассажирларны регуляр йөртүнең маршрут картасында түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

1) пассажирларны регуляр йөртүнең маршрут картасын биргән җирле үзидарә органының исеме;

2) пассажирларны регуляр йөртүнең маршрут картасының исәп саны;

3) пассажирларны регуляр йөртү маршрутының теркәү саны;

4) пассажирларны регуляр йөртү маршрутының тәртип саны;

5) чикләрендә әлеге маршрут буенча башлангыч тукталыш пункты һәм соңгы тукталыш пункты урнашкан пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча башлангыч тукталыш пункты һәм соңгы тукталыш пункты исеме рәвешендә пассажирларны регуляр йөртү маршрутының атамасы;

6) исеме, урнашкан урыны (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме, әгәр булса, атасының исеме (шәхси эшмәкәр өчен), әлеге маршрут буенча пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыручы салым түләүченең идентификацион номеры;

7) транспорт чарасының төре һәм транспорт чарасының классы;

8) транспорт чарасының экологик характеристикалары;

9) әгәр Федераль закон нигезендә чикләнгән срокка бирелсә, пассажирларны регуляр йөртү маршрут картасының гамәлдә булу вакыты;

10) транспорт чараларының пассажирларны регуляр йөртү сыйфатына йогынты ясаучы характеристикалары, әгәр мондый характеристикалар муниципаль контракт, җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыруга таләпләр яисә пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән юридик затның, шәхси эшмәкәрнең яки гади ширкәт килешүе вәкаләтле катнашучысының конкурс заявкасы белән каралса.

39. Пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршруты картасы гади ширкәт килешүендә катнашучының берсенә бирелсә, әлеге Тәртипнең 38 пункты 6 пунктчасы белән каралган мәгълүматлар гади ширкәт килешүендә катнашучыларның һәрберсе мөнәсәбәтендә күрсәтелә.

40. Юридик затка, шәхси эшмәкәргә яки гади ширкәт килешүендә катнашучыларның берсенә бирелгән пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршрут картасы, гамәлдә булу срогын озайткан, билгеләнгән тәртиптә транспорт чарасының классын яки характеристикаларын үзгәрткән, исемен, урнашу урынын үзгәртү формасында юридик затны үзгәртеп корган очракта, шулай ук шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны үзгәргән очракта, яңадан рәсмиләштерелергә тиеш.

41. Пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршруты картасын яңадан рәсмиләштерү әлеге карта бирелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр яки гади ширкәт килешүенең вәкаләтле катнашучысы тиешле

гариза белән мөрәҗәгать иткән көннән биш көн эчендә Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 10 бүлек. Пассажирларны регуляр йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкның һәм пассажирларны регуляр йөртү маршруты картасының гамәлдә булуын туктату яки туктатып тору

42. Пассажирларны регуляр йөртү муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртү турында таныклык биргән Башкарма комитет, түбәндәге бер генә очрак булса да, әлеге таныклыкның гамәлдә булуын туктата:

1) әлеге таныклык бирелгән юридик затта, шәхси эшмәкәрдә яки гади ширкәт килешүендә катнашуыларның берсендә булган лицензияне юкка чыгару турында суд карарының үз көченә керүе;

2) әлеге таныклыкның гамәлдә булуы туктатылу турында суд карарының законлы көченә керүе;

3) әлеге таныклык бирелгән юридик затның, шәхси эшмәкәрнең яки гади ширкәт килешүе вәкаләтле катнашучысының гариза белән таныклыкның гамәлдә булуын туктату турында мөрәҗәгать итүе;

4) әлеге таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамлану, әгәр ул Федераль законның 19 маддәсе 6 өлешендә каралган срокка бирелсә;

5) пассажирларны регуляр йөртү маршрутын кире кагу турында карарның үз көченә керүе;

6) әлеге Тәртипнең 9 бүлеге белән каралган җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирларны регуляр йөртү туктатылу турында карарның үз көченә керүе һәм җайга салынучы тарифлар буенча пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыра башлау.

43. Әлеге Тәртипнең 42 пункты 1, 2, 4, 5, 6 пунктчалары белән каралган хәлләр буенча пассажирларны регуляр йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуы әлеге хәлләр башланган мизгелдән туктатыла.

44. Әлеге Тәртипнең 42 пункты 3 пунктчасы белән каралган хәлләр буенча пассажирларны регуляр йөртү муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуы башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органына, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына яисә Башкарма комитетка, әлеге таныклыкның гамәлдә булуы туктатылу турында гариза кергән көннән соң, 90 көн узгач туктатыла.

Күрсәтелгән срок узганчы, мондый гариза белән мөрәҗәгать иткән юридик зат, шәхси эшмәкәр яки гади ширкәт килешүе вәкаләтле катнашучысы әлеге таныклык белән каралган пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашырырга бурычлы.

45. Пассажирларны регуляр йөртү муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр яки гади ширкәт килешүе вәкаләтле катнашучысы, пассажирларны регуляр йөртү муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру башланган көннән соң 30 көн узгач, аның гамәлдә булуын туктату турында язма формада гариза белән Башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Башкарма комитет «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында, гариза кергән көннән алып, 10 көн эчендә күрсәтлегән гариза керүе турында мәгълүмат урнаштыра.

46. Башкарма комитет түбәндәге бер генә очрак булса да, пассажирларны регуляр йөртү муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртү турында таныклыкның гамәлдә булуын туктату турында гариза белән судка мөрәҗәгать итә:

1) гадәттән тыш хәл булмаганда, пассажирларны регуляр йөртү муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртү турында әлеге таныклык белән каралган пассажирлар йөртүне рәттән өч көннән дә артык гамәлгә ашырмау;

2) әлеге таныклык бирелгән юридик затның, шәхси эшмәкәрнең яки гади ширкәт килешүендә катнашучыларның берсенең генә булса да, әлеге таныклык белән каралган пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру барышында, Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турында 11.33 маддәсе 3-5 өлешләрендә күрсәтелгән административ хокук бозулар өчен, ел дәвамында берничә тапкыр административ җаваплылыкка тартылуы;

3) гади ширкәт килешүен өзү (әгәр әлеге таныклык гади ширкәт килешүендә катнашучыларга бирелгән очракта);

4) машина йөртүче гаебе белән кеше сәламәтлегенә авыр зарар китергән юл-транспорт һәлакәте булу.

47. Пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршрут карталарының гамәлдә булуы әлеге маршрут буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык гамәлдән чыккан көнне туктатыла, әгәр пассажирларны регуляр йөртү муниципаль контракт нигезендә гамәлгә ашырылган очракта, әлеге контракт гамәлдән чыккан көнне.

48. Пассажирларны регуляр йөртү муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртү турында таныклыкның, җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыру өчен бирелгән пассажирларны регуляр йөртүнең муниципаль маршрут карталарының гамәлдә булуы автомобиль транспорты белән пассажирларны йөртү буенча эшчәнлекне тормышка ашыруга лицензиянең гамәлдән чыгу очрагында туктатыла.

## 11 бүлек. Пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыру турында хисаплар

49. Муниципаль котракт төзегән пассажир йөртүче яисә пассажирларны регуляр йөртү муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән пассажир йөртүче әлеге муниципаль контракт төзегән яисә әлеге таныклыкны биргән Башкарма комитетка пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыру турында квартал саен хисаплар тапшыра.

50. Пассажирларны регуляр йөртүне гамәлгә ашыру турында квартал саен тапшырыла торган хисапларның формасы һәм бу хисапларны Башкарма комитетка җибәрү сроклары транспорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү буенча һәм норматив-хокукый көйләү функциясен үтәүче башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнә.